| СОВЕТ БОЛЬШЕКАЙБИЦКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КАЙБЫЧ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 02 нче сентябре Олы Кайбыч авылы № 14

«Даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләме нормативлары, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләме һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында»гы 2018 елның 30 апрелендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында»гы РФ Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге 96 нчы номерлы карары нигезендә («Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Кагыйдәләре», «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасы» белән бергә), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләме нормативлары, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләме һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында»гы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Советы тарафыннан расланган 2018 елның 30 апрелендәге 4 номерлы карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 9 нчы номерлы кушымтаның 1 пунктында:

«бәлки», «җирле үзидарә органы (Муниципаль орган) җитәкчесе теләгәнчә» сүзтезмәләрен төшереп калдырырга;

«түләргә» сүзен «түләнә» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга, http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең

рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Кайбыч авыл җирлеге башлыгы А.И. Рәхмәтуллин